СОВЕТ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

площадь Советская, д.14, г.Арск, 422000

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

Совет мәйданы, 14 нче йорт, Арча шәһәре, 422000

Тел. (84366)3-11-33, факс (84366)3-01-33, 3-14-33. E-mail: archa@tatar.ru. www.arsk.tatarstan.ru

**Арча район Советы**
**КАРАРЫ**

**« 16 » апрель 2024 ел** **№ 277**

**«Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы территориясендә муниципаль урман контроле турындагы нигезләмәне раслау хакында» Арча район Советының 2021 елның 12 ноябрендәге 99 номерлы карарына (28.02.2022 №126, 25.04.2023 № 215, 14.11.2023 №238 үзгәрешләр белән) үзгәрешләр кертү турында**

Россия Федерациясе Урман кодексының 84 һәм 98 статьяларына, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы федераль законнарга ярашлы рәвештә, Арча район Советы карар бирде:

1. «Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы территориясендә муниципаль урман контроле турындагы нигезләмәне раслау хакында» Арча район Советының 2021 елның 12 ноябрендәге 99 номерлы карарына (28.02.2022 №126, 25.04.2023 № 215, 14.11.2023 №238 үзгәрешләр белән ) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. «Муниципаль урман контролен гамәлгә ашырганда мәҗбүри таләпләрне бозу куркынычы индикаторлары» дигән 2 нче кушымтаны әлеге карарга кушымта нигезендә яңа редакциядә бәян итәргә.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Арча муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә (http://arsk.tatarstan.ru).

3. Әлеге карарның үтәлешен ктикшереп торуны Арча район Советының законлылык, җәмәгать тәртибен саклау һәм җирле үзидарә буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Арча муниципаль районы башлыгы,
Арча район Советы рәисе И.Г. Нуриев

Арча район Советының
16 апрель 2024 ел, №277
карарына кушымта

**Муниципаль урман контролен гамәлгә ашырганда мәҗбүри таләпләрне бозу куркынычы индикаторлары**

Муниципаль урман контролен гамәлгә ашырганда мәҗбүри таләпләрне бозу куркынычының түбәндәге индикаторлары билгеләнә:

1) календарь елында урманны торгызу буенча Татарстан Республикасы территориясендә уртача күрсәткеч белән чагыштырганда шул ук вакыт аралыгында эш башкарган контрольдә тотылучы затның утырту (чәчү) урыннары белән сакланып калган үсемлекләр утырту (чәчү) урыннары нисбәтенең биш һәм аннан да күбрәк процентка кимүе.

2) календарь елында шул ук вакыт аралыгында Татарстан Республикасы территориясендә уртача күрсәткеч белән чагыштырганда урман үстерү буенча эш башкарган контрольдә тотылучы затның утырткан яки чәчкән урыннары саныннан булган үсемлекләр яки үсентеләр нисбәтенең биш һәм аннан да күбрәк процентка кимүе.

3) агачны кабул итү, ташу, эшкәртү һәм саклау, агачны исәпкә алу һәм аның белән килешүләр өлкәсендә үткәрелә торган операцияләр күләменең (куб.м) алдагы календарь елның шул ук чоры белән чагыштырганда бер ел эчендә агачны исәпкә алуның бердәм дәүләт автоматлаштырылган мәгълүмат системасы һәм аның белән килешүләр буенча әзерләнгән һәм сатып алынган агач күләмен тиешле дәрәҗәдә арттыру турында мәгълүмат булмаганда (2023 елдан - урман комплексының федераль дәүләт мәгълүмат системасы мәгълүматлары буенча) өч тапкыр һәм күбрәккә артуы.

4) соңгы өч календарь елда сатылган агачның күләме (куб.м) соңгы өч календарь елда әзерләнгән һәм сатып алынган агачның гомуми күләменнән (куб. м) артуы.

5) урманнарны файдалы казылмалар табу һәм чыгару өчен куллану;

6) аучылык хуҗалыгы өлкәсендә эшчәнлек төрләрен гамәлгә ашыру;

7) урман эшкәртү инфраструктурасын урнаштыру.